**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районы Иске Имән**
**авыл жирлеге**

**КАРАР**
**06.09.2018**

**КАРАР**
**№ 92**

Иске Имән авыл җирлеге Советының 2007 елның 20 маендагы 10 номерлы карары белән расланган «Иске Имән авыл җирлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм алып китү тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 766 номерлы карары нигезендә Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2 бүлекнең 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сыек көнкүреш калдыклары» - хуҗалык - халыкның тереклек эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм үзәкләштерелгән су чыгару системасына тоташтырылмаган (технологик яктан тоташтырылмаган) һәм агып төшүче суларны кабул итү һәм туплау өчен билгеләнгән корылмаларга һәм җайланмаларга ташлана торган көнкүреш агым сулары.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе

Р.Ә.Исламова